**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «26» маеннан № 223

**«Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга саву аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга саву аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 195 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

«2016 елда өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сатып алынган саву аппаратлары өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе»нең 1 кушымтасында:

2.3. пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалыкта савым сыерлары үлгән яисә аларны мәҗбүри суйган очракта, кабул ителгән йөкләмә чоры тәмамланганчыга кадәр, гражданнар авыл җирлекләре башкарма комитетларына ветеринария белешмәләре һәм терлекне билгеләнгән тәртиптә бракка чыгару актларын тапшыра.»;

2.10 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты бюджет акчаларын алган көннән алып биш көн эчендә гражданнарның исәп-хисап счетларына субсидияләр күчерә.».

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**